# Шәфикъ Иматдинов – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булырга лаеклы шагыйрь

**17 нче китапханәдә Шәфикъ Иматдиновның «Йөрәк сәгате» җыентыгы укучыларга тәкъдим ителде.**

Күптән түгел генә өлкәбездә яшәп иҗат итүче талантлы шагыйрь, милли хәрәкәт активисты Шәфикъ Иматдиновның «Йөрәк сәгате» дип исемләнгән өченче китабы дөнья күрде. Күркәм традиция буенча Ульяновскиның 17 нче санлы милли китапханәсендә яңа гына табадан төшкән әлеге җыентыкны укучыларга тәкъдим итү кичәсе үткәрелде. Әдәби-музыкаль кичәдә автономия вәкилләре, каләм осталары һәм шигърият сөюче милләттәшләребез катнашты.

Очрашуны өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рамис Сафин башлап җибәрде. Шәфикъ абыйның күпкырлы иҗаты соклану тудыра, ул – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булырга тулысынча лаеклы шагыйрь, диде Р.Сафин. Мөхтәрият җитәкчесе җыентыкның исеменә тәңгәл китереп, авторга сәгать бүләк итте.





Ә китапның редакторы, «Өмет» газетасының баш мөхәррире Исхак Хәлимов авторның милләт, дин, тел темасын беренче урынга куюы, шигырьләренең искиткеч тормышчан булуы турында сөйләде. Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Равил Шәфигуллин һәм Иделбикә, Димитровград шәһәре каләм осталары Ринат Илькин һәм Гөлсинә Ханәфи, Чынлы төбәге шагыйрәсе Нәҗия Шагаева, Ишеевка бистәсеннән танылган журналист Сәгыйть Бәдретдинов, Ульяновскиның күренекле каләм ияләре Флорис Галимьянов һәм Иркәм Хәйретдинов үзләренең каләмдәшләре Шәфикъ Иматдиновка яңа иҗат уңышлары теләделәр һәм шигырьләрен яңгыраттылар. Бер чишмә суларын эчеп, бер үк болыннарда уйнап үскән якташы – күрше Чүпрәле районы шагыйре Азат Вахитов та Шәфикъ абыйның казанышларына чиксез шатлануын белдерде. Йөрәктән чыккан шигырьләр генә кеше күңеленә үтеп керә, Сезнең иҗатыгыз нәкъ шундый инде, диде ул. Татар шигърияттән өзелеп сөюче танылган педагог Әсхать Рәхимовның чыгышы да күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Өстәл китабына тиң җыентыкта гади генә язылып, олы фикерләр тудыручы шигырьләр тупланган, диде ул. Сенгилей районы Красный Гуляй мәктәбенең 10 сыйныф укучысы Эльмира Сабитова авторның шигырьләрен ифрат та сәнгатьле укыды. Ә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлфәрия Латыйпова, Сембер татар сәхнәсе йолдызлары Җәмилә Мифтахова һәм Зөлфия Мусеева кичәне моңлы җырлары белән бизәделәр.

Шигърият, җыр-моң кичәсе бик тә күңелле үтте. Шәфикъ Иматдиновның барлык китапларын, шул исәптән «Йөрәк сәгате» җыентыгын да әзерләп чыгаручы «Өмет» газетасы редакциясе коллективына һәм 17 нче санлы милли китапханә хезмәткәрләренә рәхмәт сүзләре яңгырады.

Соңыннан Ульяновск өлкәсенең татар язучылары берләшмәсе әгъзалары чәй өстәле артында фикер алыштылар. 2017 елга эш планын раслап, «Сембер язлары» әдәби альманахының алтынчы чыгарылышын нәшер итү кирәклеген ассызыкладылар. Актив җәмәгать эшлеклесе, танылган журналист һәм краевед Наилә Потеева яшьләрнең, мәктәп укучыларының татар телендә укый һәм яза белмәүләре, милләт тарихы белән кызыксынмаулары турында ачынып сөйләде.

**Рузия ХӘЛИМОВА.**